**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об образовании Инвестиционного совета Республики Татарстан»**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 5 июля 2012 года № УП-538 «Об образовании Инвестиционного совета Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 6 сентября 2012 года № УП-745, от 3 ноября 2012 года № УП-914, от 20 марта 2013 года № УП-242, от 29 марта 2013 года № УП-258, от 8 августа 2013 года № УП-717, от 29 апреля 2014 года № УП-440, от 27 августа 2014 года № УП-826, от 2 марта 2015 года № УП-199, от 13 октября 2015 года № УП-984, от 29 июня 2016 года № УП-553, от 8 июня 2017 года № УП-480, от 4 сентября 2018 года № УП-612, от 8 февраля 2019 года № УП-90, от 12 октября 2019 года № УП-619, от 28 марта 2020 года № УП-206 и от 26 ноября 2020 года № УП-782), следующие изменения:

а) преамбулу Указа изложить в следующей редакции:

«В целях реализации Закона Республики Татарстан от 25 ноября 1998 года № 1872 «Об инвестиционной деятельности в Республике Татарстан» **постановляю:**»;

б) в Положении об Инвестиционном совете Республики Татарстан:

дополнить пунктом $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. Основными целями Инвестиционного совета являются:

создание благоприятного инвестиционного климата в Республике Татарстан;

выработка мер по улучшению инвестиционного климата, обеспечению стабильных условий осуществления инвестиционной деятельности и реализации инвестиционных проектов на территории Республики Татарстан;

защита прав и законных интересов субъектов инвестиционной деятельности;

разрешение разногласий и споров инвесторов с органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления в Республике Татарстан, уполномоченными организациями по вопросам реализации инвестиционных проектов на территории Республики Татарстан, не урегулированных Агентством инвестиционного развития Республики Татарстан, в досудебном порядке.»;

пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4. В функции Инвестиционного совета входит:

а) разработка предложений по:

размещению на территории Республики Татарстан объектов в рамках реализации инвестиционных проектов и программ;

организации взаимодействия исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан и лиц, участвующих в инвестиционном процессе;

уменьшению административных барьеров, в том числе в части сокращения сроков и упрощения процедуры выдачи разрешительной документации;

приоритетным направлениям развития Республики Татарстан и координации финансовых и инвестиционных ресурсов на наиболее важных направлениях;

государственной поддержке инвестиционных процессов и стимулированию инвестиционной активности на территории Республики Татарстан;

установлению единых требований к основным критериям инвестиционных проектов, поддерживаемых за счет средств федерального бюджета и бюджета Республики Татарстан;

б) рассмотрение вопросов, связанных с:

нарушением положений Инвестиционной декларации Республики Татарстан;

исполнением обязательств Республики Татарстан и инвесторов при реализации инвестиционных проектов и программ;

в) оценка последствий принятия проектов нормативных правовых актов, регламентирующих инвестиционную деятельность в Республике Татарстан.»;

в) в составе Инвестиционного совета Республики Татарстан (далее – Инвестиционный совет):

ввести в состав Инвестиционного совета:

Егорова Андрея Юрьевича – директора муниципального унитарного предприятия города Казани «Водоканал» (по согласованию);

Хазиева Раузиля Магсумяновича – генерального директора акционерного общества «Татэнерго» (по согласованию);

изложить в следующей редакции наименования должностей членов Инвестиционного совета:

Ш.Р. Агеева – «председатель Союза «Торгово-промышленная палата Республики Татарстан» (по согласованию)»;

Р.С. Яруллина – «генеральный директор акционерного общества «Татнефтехиминвест-холдинг» (по согласованию)».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
23 декабря 2021 года
№ УП-990

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2012 елның 3 ноябрендәге ПУ-914 номерлы, 2013 елның 20 мартындагы ПУ-242 номерлы, 2013 елның 29 мартындагы ПУ-258 номерлы, 2013 елның 8 августындагы ПУ-717 номерлы, 2014 елның 29 апрелендәге ПУ-440 номерлы, 2014 елның 27 августындагы ПУ-826 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-199 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-984 номерлы, 2016 елның 29 июнендәге ПУ-553 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы, 2018 елның 4 сентябрендәге ПУ-612 номерлы, 2019 елның 8 февралендәге ПУ-90 номерлы, 2019 елның 12 октябрендәге ПУ-619 номерлы, 2020 елның 28 мартындагы ПУ-206 номерлы һәм 2020 елның 26 ноябрендәге ПУ-782 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Указның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында **карар бирәм:**»;

б) Татарстан Республикасы Инвестиция советы турында нигезләмәдә:

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункты өстәргә:

«$2^1$. Инвестиция советының төп максатлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасында уңайлы инвестиция климаты булдыру;

Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция климатын яхшырту, инвестиция эшчәнлеген тормышка ашыру һәм инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен тотрыклы шартларны тәэмин итү буенча чаралар эшләү;

инвестиция эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;

инвесторларның Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, вәкаләтле оешмалар белән Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы тарафыннан җайга салынмаган фикер каршылыкларын һәм бәхәсләрен судка кадәрге тәртиптә хәл итү.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Инвестиция советының эшенә түбәндәгеләр керә:

а) түбәндәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү:

инвестиция проектларын һәм программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә объектлар урнаштыру;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм инвестиция процессында катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген оештыру;

рөхсәт документларын бирүнең вакытын кыскарту һәм процедураларны гадиләштерү өлешендә административ киртәләрне киметү;

Татарстан Республикасын үстерүнең өстенлекле юнәлешләре һәм аеруча мөһим тармакларга финанслар һәм инвестиция ресурсларын кертүне координацияләү;

Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция процессларына дәүләт ярдәме күрсәтү һәм инвестиция активлыгын арттыруга кызыксындыру уяту;

федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына ярдәм күрсәтелә торган инвестиция проектларының төп критерийларына бердәм таләпләр билгеләү;

б) түбәндәгеләр белән бәйле мәсьәләләрне карап тикшерү:

Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе нигезләмәләрен үтәмәү;

инвестиция проектларын һәм программаларын тормышка ашырганда Татарстан Республикасы һәм инвесторлар йөкләмәләрен үтәү;

в) Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген җайга салучы норматив хокукый актлар проектларын кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләү.»;

в) Татарстан Республикасы Инвестиция советы (алга таба – Инвестиция советы) составында:

Инвестиция советы составына кертергә:

Егоров Андрей Юрьевичны – Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе директорын (килешү буенча);

Хаҗиев Рәүзил Мәгъсүмҗан улын – «Татэнерго» акционер җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча);

Инвестиция советы әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ш.Р. Агиевның – «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» Берлеге рәисе (килешү буенча)»;

Р.С. Яруллинның – «Татнефтехиминвест-холдинг» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 23 декабрь
№ ПУ-990